РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«10» апреля 2023 ел г. Альметьевск № 868

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Муниципаль милектәге җир кишәрлегеннән түләүсез файдалану өчен торглар үткәрмичә муниципаль милеккә, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 22 ноябрендәге 1667 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, 2010 елның 27 июлендәге «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 210-ФЗ номерлы федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Муниципаль милектәге җир кишәрлегеннән түләүсез файдалану өчен торглар үткәрмичә муниципаль милеккә, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 22 ноябрендәге 1667 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 22 июлендәге 1547 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарга 1 нче кушымтада:

- 2 бүлекнең 2.6.1 пунктындагы 22) пунктчасында түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«22) инвалидлык билгеләү фактын раслый торган белешмәләр - Россия Федерациясе пенсия һәм социаль иминләштерү фонды;»;

- 2 бүлекнең 2.8.2.1 пунктындагы 13) пунктчасында «бакчачылыкны» сүзен «гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык алып барулары» сүзләренә алмаштырырга;

- 3 бүлекнең 3.3.2.1 пунктындагы унберенче абзацын түбәндәге

редакциядә бәян итәргә:

«Формалаштырылган гаризаны формаль-логик тикшерү орган (оешма) билгеләгән таләпләр нигезендә, мөрәҗәгать итүче һәр кырны электрон рәвештәге кырны тутыру процессында автомат рәвештә бердәм портал тарафыннан гамәлгә ашырыла. Бердәм портал тарафыннан тутырылган электрон рәвештәге кырның корректлы булмаса да, мөрәҗәгать итүче ачыкланган хатаның характеры һәм аны мәгълүмати хәбәр итү юлы белән сорауның электрон формасында бетерү тәртибе турында хәбәр итә.».

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары вазыйфаларын башкаручы А.А. Җамалетдиновка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе А.М. Каюмов